МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.01.2019 г.Казань № 8

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 31 гыйнварендә теркәлде, № 5418

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.01.2019 ел. № 8 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 05 июлендәге 514 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2014 № 309, 22.06.2015 № 425, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 350, 07.05.2018 № 347, 19.09.2018 № 892 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.4.2 пунктта 2 пунктчаның беренче абзацында «Интернет» челтәре ярдәмендә» сүзләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре (алга таба – «Интернет» челтәре) ярдәмендә» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

ундүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

егерме өченче абзацта «мәгълүмат-телекоммуникация» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.3.2 пунктның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар, гариза һәм документлар шәхсән кабул ителгәндә яисә почта аша килгәндә, гариза һәм документлар килгән көнне гамәлгә ашырыла; гариза «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша килгән очракта, – гариза һәм документлар Идарәгә (бүлеккә) килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Идарәнең (бүлекнең) эш сәгатьләре тәмамланган вакытта килсәләр, киләсе көнне. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Идарәнең (бүлекнең) ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.»;

3.3.4 пунктның җиденче абзацында «алты» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3.3.5 пунктның икенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3.3.6 пунктның икенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3.5.1 пунктның бишенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3.5.2 пунктның икенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

3.5.3 пунктның икенче абзацында «бер» сүзеннән соң «эш» сүзен өстәргә;

5 бүлек аталышын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының (хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең


карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.3 пункттагы икенче абзацта «мәгълүмат-телекоммуникация» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

«Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә эшләрнең эзлеклелеге буенча блок-схема






2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләүдәге чыгымнарга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 17 сентябрендәге 856 номерлы боерыгы белән расланган Күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонтлауга кертем түләүдәге чыгымнарга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Компенсация ялгыз яшәүче эшләми торган, җитмеш һәм аннан да өлкәнрәк яшенә җиткән торак урын милекчеләренә, шулай ук җитмеш һәм аннан да өлкәнрәк яшенә җиткән, эшләми торган, 60 һәм 55 яшенә җиткән (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) гражданнардан гына һәм эшләми торган I һәм (яки) II төркем инвалидларыннан торучы гаилә составында яшәүче торак урын милекчеләренә бирелә.»;

2 бүлекнең «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктның беренче абзацында «килгән» сүзен «теркәлгән» сүзе белән алмаштырырга;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына туры китерелгән формада компенсация бирү турында гариза;

үзенә карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгеләүче документларның күчермәләре.;

компенсация алу хокукы булган гражданнарның гаилә әгъзаларына

инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы документларның күчермәләре.

Үзәктә компенсация алу хокукы булган гражданнарның гаилә әгъзаларына инвалидлык билгеләнү фактын раслаучы документ булган очракта, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документны тапшыру зарурлыгыннан азат ителә.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Дәүләт хезмәтен алучыларның законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, дәүләт хезмәтен алучының мәнфәгатьләрен белдерүгә үзләренең вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документны, банкта яки бүтән кредит учреждениесендә ачтырылган шәхси счет реквизитларын тапшыра (алуның аталган ысулын сайлаган очракта).

Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхес таныклаучы документ күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, электрон саклагычлардан һәм (яки) гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша да, җибәрелергә мөмкин.»;

3.3.1 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон саклагыч җайланмаларыннан һәм «Интернет» челтәреннән файдаланып тапшырылырга мөмкин.»;

тугызынчы һәм унынчы абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«шәхсән кабул иткәндә яисә гариза һәм документлар почта аша килгәндә – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза һәм документлар почта аша, шул исәптән электрон почта аша яки, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша электрон документлар формасында килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлегенә килгән көндә яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе эш көнендә. Гариза

һәм документлар (документларның күчермәләре) электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.»;

3.5.1 пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гарызнамәләргә җаваплар килгән көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көнненән дә соңга калмыйча.»;

5 бүлек аталышын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең) вазыйфаи затының (хезмәткәренең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе».